# Изложение
# 3 класс
# Песи



Абдуллина Лилия Котдусовна
учитель начальных классов
МАОУ «СОШ№4»
г. Набережные Челны

http://aida.ucoz.ru

# Укучыга искәртмә

2. Текстны игътибар белән тыңла. Сорауларга җавап бирергә әзерлән.
3. Текстка исем куй.

3. План төзе.

4.План буенча сөйлә. Иптәшләреңне тыңла.

5.Изложение яз.

6.Тикшереп чык, эчтәлекне дөрес итеп бирдеңме, еш кабатланучы сүзләр юкмы?

7.Сүзләрнең дөрес язылышын тикшер.

8.Тыныш билгеләренең куелышын тикшереп чык.

http://aida.ucoz.ru

# Текст белән танышу

## Песи.

Минем кап-кара песием бар.Үзе бик матур. Йолдызкай исемле. Иртән минем белән бергә йокыдан тора. Бергәләп зарядка ясыйбыз. Аннан соң икебез дә юынабыз. Песи юынырга су янына барып тормый. Алгы тәпиләре белән битен һәм колак артларын юа. Көндез ул ялгызы була. Шулай да үзен тәртипле тота. Безнең мәктәптән кайтуны зарыгып көтә. Рөхсәтсез бер әйбергә дә тими. Ап-ак тәпиләрен бик чиста итеп саклый. Чиста тәлинкәдән сөт эчәргә бик ярата. Безнең тәртипле песигә күршеләр дә соклана.

http://aida.ucoz.ru

# Текстка карата сораулар

1. Минем нинди песием бар?
2. Аның исеме ничек?
3. Иртән песи минем белән бергә нишли?
4. Көндез песи үзен ничек тота?
5. Йолдызкай нишләргә бик ярата?
6. Күршеләр песигә ни өчен соклана?

http://aida.ucoz.ru

# Текстны өлешләргә бүл

Минем кап-кара песием бар.Үзе бик матур. Йолдызкай исемле.

Иртән минем белән бергә йокыдан тора. Бергәләп зарядка ясыйбыз. Аннан соң икебез дә юынабыз. Песи юынырга су янына барып тормый. Алгы тәпиләре белән битен һәм колак артларын юа.

Көндез ул ялгызы була. Шулай да үзен тәртипле тота. Безнең мәктәптән кайтуны зарыгып көтә. Рөхсәтсез бер әйбергә дә тими. Ап-ак тәпиләрен бик чиста итеп саклый. Чиста тәлинкәдән сөт эчәргә бик ярата.

Безнең тәртипле песигә күршеләр дә соклана.

http://aida.ucoz.ru

# План төзү

1. Йолдызкай- матур песи.
2. Песинең көндәлек режимы бар.
3. Безнең песи чисталык ярата.
4. Тәртипле Йолдызкайга күршеләр дә соклана.

http://aida.ucoz.ru

# Текстны кабатла

Мине  бар.Үзе бик матур. Йолдызкай исемле.



Иртән минем белән бергә йокыдан тора. Бергәләп ясыйбыз. Аннан соң икебез дә юынабыз.Песи юынырга су янына барып тормый. Алгы тәпиләре белән битен һәм колак артларын юа.

Көндез ул ялгызы була. Шулай да үзен тәртипле тота. Безнең мәктәптән  уны зарыгып көтә. Рөхсәтсез бер әйбергә д ı. Ап-ак тәпиләрен бик чиста итеп сакл иста тәлинкәдән сөт

бик ярата.

Безнең тәртипле песигә күршеләр дә соклана.

# Сүзлек эше
# Төшеп калган хәрефләрне куй

Йолд_зкай, йок_дан тора, көнд_з, рө_сәт, _чә,

а_ _ ан со_, ю_на.

**Җәяләрне ач:**

Икебез (дә), шулай (да),күршеләр (дә)

http://aida.ucoz.ru

# Синонимнар тап:

Юына- ______________________

Ялгыз- ______________________

Тәртипле- ____________________

Тәпи- ________________________

Чиста- _______________________

Ярата- ______________________

Песи- _____________________

http://aida.ucoz.ru

# Антонимнар тап:

Иртә- ____________________

Матур- ____________________

Бергәләп - ____________________

Алгы- ____________________

Ап-ак- ____________________

Чиста- ____________________

http://aida.ucoz.ru

# Лексик эзерлек:

Сүзнең мәгънәсен аңлат:

**Зарыгып-___________________**

**Рөхсәтсез-___________________**

Башкача әйтеп кара:

**Безнең тәртипле песигә күршеләр дә соклана.**

http://aida.ucoz.ru

# План буенча эчтәлекне сөйлә:

1. Йолдызкай –матур песи



http://aida.ucoz.ru

# 2. Песинең көндәлек режимы бар.








http://aida.ucoz.ru

# 3. Безнең песи чисталык ярата.



http://aida.ucoz.ru

# 4. Тәртипле Йолдызкайга күршеләр дә соклана.



http://aida.ucoz.ru

# Изложение .
# Песи.

1.Йолдызкай- матур песи.
2.Песинең көндәлек режимы бар.
3.Безнең песи чисталык ярата.
4.Тәртипле Йолдызкайга күршеләр дә соклана.

<u>**Терәк сүзләр**</u>: йокы, зарядка, юынабыз, барып тормый, ялгыз, тәртипле, зарыгып кötә, рөхсәтсез, саклый, күршеләр

http://aida.ucoz.ru

## Кулланылган Интернет- ресурслар :


http://www.varieta.ru/forum/topic.html?id=100&p=18

http://fotki.yandex.ru/users/mkelka/view/219838/

http://www.dietaonline.ru/community/post.php?topic_id=37789&page=14

http://www.1tv.ru/news/other/164990-

http://www.darchik.ru/rjirf

http://www.dietaonline.ru/community/post.php?topic_id=37789&page=14


http://aida.ucoz.ru